


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№3 Ноябрь, 2024 ел*

**24 нче ноябрь – кадерле Әниләребезнең бәйрәме. Бәйрәмегездә Сезгә озын, сәламәт гомер, тыныч тормыш һәм эшегездә зурдан - зур уңышлар телибез. Йөзегездән гел елмаю китмәсен,шатлык кына балкысын.**




Балагызның берәве сез,
Гаиләнең йөрәге сез,
Иминлекнең терәге сез,
Һәркемнең иң кирәге сез.

Әни... якты кояшка тиң, иң кадерле кеше. Дөньяда бәлки шулкадәр якын, ягымлы, ярдәмче кеше юктыр. Кеше кайда гына булса да, ни эшләсә дә, иң кирәк урын – әни янында, туган йортта. Ул һәрберебез өчен иң кадерле, иң яхшы, иң матуры, гомумән, тормышта иң әһәмиятле кеше. “Әни, әнием, әнкәй” - дип назлап әйтәбез дә, күңелебездәге бөтен хис-кичерешләребезне шул гади сүзгә салабыз. Ә бит шушы өч хәрефтән торган сүзне күпме наз, җылылык һәм күңел тойгысы белән әйтәбез!


Хатын-кызның иң югары бурычы – әни булудыр, чөнки “әни” - бала әйткән беренче сүз. Бу сүз дөньяның күпчелек телләрендә бер үк төрле яңгырый һәм дөньяда иң якын, иң яраткан кешене атый.

Нәкъ менә шул сыйфатлар җәмгыятькә әниләр көнен игълан итәргә сәбәп булгандыр. Россия Федерациясе Президентының 1998 елның 30 гыйнварында чыккан 120 номерлы карары нигезендә, илебездә ноябрь аеның соңгы якшәмбесе ел саен “Әниләр көне” булып билгеләп үтелә. Быел ул 24 ноябрь көненә туры килә.

Илебездә билгеләп үтелә торган күпсанлы бәйрәмнәр арасында әниләр көне аерым урын алып тора. Бәйрәмнең максаты – хатын-кызга сакчыл караш традицияләрен хуплау, гаилә нигезләрен ныгыту, безнең тормышта төп кешенең – әнинең әһәмиятен аеруча билгеләп үтү. Бу бәйрәм беркемне дә битараф калдыра алмый. Нәкъ әниләр көнендә үз балаларына мәхәббәт, игелек, наз бүләк итүче барлык аналарга рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Тик нинди генә җылы сүзләр әйтмәсәк тә, җитмәс төсле... Әниләр көне – искиткеч көн! Безнең һәрберебез әниебезне искә төшерергә, аңа шалтыратырга, бәлки янына кайтып, аны котларга, аның сәламәтлеге һәм кәефе ничек булуы белән кызыксынырга тиешле көн! Халык мәкалендәге бик акыллы сүзләрне искә төшерик:” Җәннәт бакчасы – әниләрнең аяк астында!”

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## Әниемнең җылы кочагы



Минем өчен иң кадерле кеше - әнием. Аның исеме - Гатауллина Фирдауся Әнсафовна. Шатлыкта да, авыр чакларда да мин әнием турында уйлыйм, аннан киңәшләр сорыйм. Әнием Чупрәле мәктәбен “5” билгеләренә генә тәмамлап, Казан шәһәрендә югары уку йортында бухгалтер белгечлеген ала һәм күп еллар туган якларында үз һөнәре буенча эшли. Минем әнием шундый сөйкемле, гел безгә булышучы. Әнисез өйнең яме, нуры да юк. Җылы өйдә каршы алмаса, миңа бик күңелсез. Әни безнең өчен яши. Кеше арасында ким-хур булмасыннар дип тырыша. Нинди генә кыенлыклар килсә дә, сиздерми. Безне тырыш, гадел булырга өйрәтә. Әнием минем өчен гел үрнәк булып тора, чөнки ул сабыр, эшчән, кешеләр белән аралашучан, кунакчыл, олы җанлы.

Әнием татар халык ашларын бик оста пешерә. Аннан да тәмле пешерүче бармы икән?! Бу дөньяда иң әйбәт, иң акыллы, иң матур, иң сабыр кеше кем ул? - дигән сорауга мин бер дә икеләнмичә: “Ул - минем әнием!” - дип әйтер идем.

Рәхмәт, әни, сиңа барсы өчен. Җил-яңгыр тидерми безне саклап үстергәнең өчен.

**10 нче сыйныф укучысы Гатауллина Илүзә**

## Мәктәбебездә Әниләр көне

Әниләр көне уңаеннан мәктәбебездә күптөрле чаралар булып узды. 22 нче ноябрь көнне башлангыч сыйныф укучылары һәм аларның сыйныф җитәкчеләре тырышлыгы белән әниләр өчен зур концерт оештырылды. Укучылар әниләрен котлап җырлар җырладылар, шигырьләр сөйләделәр, биеделәр. Бәйрәм ахырында үз куллары белән ясалган открыткаларын әниләренә бүләк иттеләр. Шулай ук һәр сыйныф Әниләр көненә багышлап, бәйрәм белән котлап бик матур эчтәлекле видеороликлар ясап, әниләренә җиткерделәр.

Әни дөньядагы иң кадерле, иң якын кеше. Без аларның ярдәмен, игътибарын, яратуын һәрчак тоябыз. Үзебез дә аларга булышырга тырышабыз.

Әниләр, әбиләр, апалар, бәйрәмегез белән! Сезгә саулык-сәламәтлек, озын гомер телибез. Кадер-хөрмәттә, якыннарыгыз янәшәсендә тыныч, имин гомер кичерергә язсын.

**6 нчы сыйныф укучысы Халикова Фирүзә**

## “Яшь җәяүленең дуслары”

Жир йөзендә яшәгән ди, булган ди бер акыллы, тәртипле малай. Аның исеме Шәвәли булган. Җәй көне ул авылда әбиләрендә ял иткән. Ул гел урманга барырга яраткан. Чөнки аның дуслары куян, төлке, бүре икән. Ул алар белән уйнаган, урман сыйлары белән сыйланган. Көз җиткәч, ул дуслары белән саубуллашкан. Шәвәли беркөнне дусларын үзенә кунакка шәһәргә чакырырга уйлаган. Ул аларга телеграмма җибәргән.

Телеграмманы алуга җәнлекләр бик сөенгәннәр. Урман күчтәнәчләрен гөмбәләрне, миләшләрне, баланнарны җыеп юлга кузгалганнар. Алар шәһәргә килеп җиткәч, зур йортларны, җиңел автомобиль транспортын, йөк машиналарын күргәч, аптырап калганнар. Светофорны күргәч, шаккатканнар. Кая барырга белми чабып йөргәннәр. Ләкин аларны полиция хезмәткәре туктаткан.Юлны аркылы чыкканда игътибарлы булыгыз дип кисәткән! Җәяүлеләр кичүе аша чыгыгыз, башта сулга, аннан уңга карарга кирәк,- дип аңлатканнар. Светофорның кызыл төсендә – туктарга, сары төсендә көтәргә, яшел ут – хәрәкәт итәргә ярый дигәннәр. Җәнлекләр бик куанып һәм рәхмәт әйтеп, юлларын дәвам иткәннәр. Ләкин куянның тыңлыйсы да килмәгән. Трамвайда барганда акча да түләмәгән. Аның артыннан “куян, куяяян” дип кычкырып калганнар. Ул светофорның кызыл төсенә чабып кергән. Аны аздан гына машина бәреп китмәгән. Аны коткарам дип төлке аягын авырттырган. Җәнлекләр бик тә борчылганнар.

Төлкенең аягын табиб караган, аны кысып бәйләп куйган. Куян бик борчылган төлке өчен, чөнки аның дусты аның аркасында бәлага юлыкты бит. Бу хәлне Шәвәли ишетеп алган. Тиз генә дуслары янына ашыккан. Шәвәли табибка рәхмәтләр әйтеп, җәнлекләрне өенә алып кайткан.Төлкене дару үләннәре белән дәвалаган. Дусларына юл йөрү кагыйдәләрен бик нык өйрәткән. Куян моннан ары гел светофорны гына карап юл аркылы чыгарга сүз биргән.

Менә төлкенең аягы да тазарган. Аларны Шәвәли урманга озаткан. Шул көннән башлап, куян юлларда куркып кына йөрүче куркак куян булып калган.

**2нче сыйныф укучысы Галявиев Ранил**

## Керпе белән куян

Борын заманда калын урманда яшәгән ди Керпе белән Куян. Алар бик тату һәм дус яшәгәннәр. Куян бик шук һәм наян булган. Керпе һәрвакытта да аңа ярдәмгә килгән.

Менә бервакыт дуслар сазлыкка мүк җиләге җыярга баралар. Куян, һәрвакыттагыча сикергәләп уйнап барган. Үзе дә сизмәстән сазлыкка кереп киткән һәм бата башлаган. Керпе тагын ярдәмгә ашыккан. Ул Куянга бер озын агач ботагы сузган. Куян таякка тотынгач, керпе аны тартып чыгарган. Менә шулай итеп, Керпе дустын үлемнән коткарган.

**4 нче сыйныф укучысы Закиржанова Дилия**



## Әниләр бәйрәме

Мәктәбебездә 22 нче ноябрь көнне “Әниләр бәйрәме “ булып узды. Без, 3нче сыйныф укучылары, бәйрәмдә биедек, күмәк җыр башкардык. Кадерле әниләребезне котлап матур шигырьләр сөйләдек. Хезмәт дәресендә үз кулларыбыз белән ясаган бүләкләребезне тапшырдык. Сыйныфташларыбыз Амира һәм Иркәнең матур итеп җырлавы барыбызга да ошады. Әниләребез бәйрәмдә рәхәтләнеп ял иттеләр. Бәйрәм өчен безгә зур рәхмәт әйттеләр.

**3нче сыйныф укучысы Юсупова Динә**

## Минем иң кадерлем



Һәркемгә үз әнисе - дөньядагы иң кадерле кеше. Миңа да әнием бик кадерле. Барлык балалар кебек, минем дә телем "әни" сүзе белән ачылган. Минем әнием бик әйбәт, сабыр,тыйнак кеше. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мин әниемә кулымнан килгәнчә булышырга, аны борчымаска тырышам. Минем әнием укытучы һөнәрен сайлаган. Ул физика - математика белгечлеге буенча укыган. Безнен мәктәптә физика фәнен укыткан, аннары Дусым балалар бакчасы мөдире булып эшләгән. Ә хәзерге көндә ул районыбызның мәгариф бүлегендә математика, БДИ буенча методист булып эшли.

Минем әнием Талия бик нечкә күңелле, сабыр холыклы, төгәл кеше. Ул безгә тәпле киңәшләре белән ярдәм итә. Ял көннәрендә без саф һавада йөрергә яратабыз.

Әниле булу- нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Әнием, мин сине бик яратам! Сиңа иң изге теләкләремне генә телим.

**9 нчы сыйныф укучысы Мөхәмәтшин Зөлфәт**






**Мин биергә яратам.**

Татар халкы элек-электән жырлы, биюле халык. Бию матурлыкка, гүзәллеккә өйрәтә. Татар яшьләре жырлы-биюле уеннарны каз өмәләрендә, аулак өйләрдә һәм башка бәйрәмнәрдә башкарганнар. Хәзер дә нинди генә бәйрәм булмасын - берсе дә жыр-биюсез узмый. Шул рәвешле халык рәхәтләнеп ял итә, күңел ача.

Мин дә биергә яратам. Бәйрәмнәрдә татар халык биюләрен яратып бии башладым. Әлбәттә, тамашачы алдына чыгып бию ихтыяр көче һәм кыюлык сорый. Бию күнегүләрен интернеттан табып өйрәнәм. Сыйныфташым Зәринә белән дәресләрдән соң калып өйрәндек. “Укытучылар көне”ндә, “Көзге уңыш бәйрәмендә чыгыш ясадык.

Ә менә мәдәният йортында әниләргә багышланган концертта без өч кыз биедек. Дустым Илүзә һәм Исламия белән биюе бигрәк рәхәт булды.

Биюләрдә татар халкының милли үзенчәлеге ачык чагыла. Алар халыкка хас булган дәрт, житезлек белән башкарыла. Шул ук вакытта татар биюе хатын-кызның тыйнаклыгы, оялчанлыгы, назлылыгы турында да сөйли.

Татар халык биюләрен туплап, аларны фәнни яктан эшкәртүгә һәм сәхнәгә куюга Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре якташыбыз Габдрахман Сәлимовның да зур өлеше кергән. Ул оештырган “Каз канаты” ансамблендә рус теле укытучысы Сания апа Фаритовна студент елларында биегән. Габдрахман Сәлимов турында Самат Шакир музеенда истәлекләр бар. Шундый сәләтле шәхесләр чыккан безнең авылдан. Безнең өчен горурлык. Безнең мәктәбебездә дә бию ансамбле оештырырга кирәк дигән фикерем бар.

**8 нче сыйныф укучысы Галимжанова Әдилә**

**Минем әти үз эшенең остасы.**

Ул эшен биш бармагы кебек төгәл белә. Аны хезмәттәшләре дә, житәкчеләр дә хөрмәт итә. Әтием Алмаз - тимер эшләре остасы. Ул тимерне төрле формага кертә, бизәкләр дә ясый. Башта сызым сыза,үлчи, исәпли. Аннан эшкә керешә. Эшен яратып башкара. Безнең өйдә дә әти эшләгән әйберләр бик күп. Соңгы вакытларда сораган кешегә капка, коймалар да эшли башлады. Эшенең нәтижәсе матур килеп чыга. Андый кешеләр турында: “Кулларыннан куан” яки “Кулларыннан гөлләр тама” диләр. Бу бик дөрес сүзләр, безнең әтигә туры килә. Без уллары, әтигә өйдә эшләгәндә булышабыз, булдырырга ярдәм итәбез. Әтиләр көне уңаеннан, әтием турында инша яздым. Мин әтине яратам, хөрмәт итәм.

**5 класс укучысы Хакимов Әсхәт**




**Туган якның моңлы жырчысы**

Сибгат Хәким 1911 елның 4 декабрендә Татарстанның Әтнә районы Күлле-Киме авылында крестьян гаиләсендә туа. 1931 елда Казанга килеп Татрабфакка укырга керә, ә икенче курстан Казан дәүләт педагогия институтына күчә. 1937 елда әлеге институтны тәмамлагач, ул Татарстан китап нәшриятында, аннары «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә эшли.

Ватан сугышы башлангач, 1941 елның июнь аенда армиягә алынып, Сибгат Хәким 1946 елның маена кадәр хәрби хезмәттә була. Сугышның башыннан ахырына кадәр диярлек фронтта көрәшә. Армиядән кайткач, ул кабат "Совет әдәбияты" журналы редакциясенә эшкә урнаша, ә 1950 елдан язучылык эше белән генә шөгыльләнә.

Шагыйрь игътибарын даими биләп торган мөһим темаларның тагын берсе— туган жир. Үзе туып үскән Казан арты төбәгенә, аның табигатенә, кешеләренә мәхәббәт хисе шагыйрьнең бөтен иҗатын озатып бара. Бу тема әдипнең күп санлы лирик шигырьләрендә, жырларында, «Үрләр аша» (1964), «Васыятьләр» (1969), «Дәверләр капкасы» (1974) кебек поэмаларында чагылыш таба.

С. Хәким — дистәләгән жырлар авторы. «Юксыну» (Ш. Мәжитов музыкасы), «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда» (халык көйләре), «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (Х. Вәлиуллин музыкасы), «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә» (М. Мозаффаров музыкасы), «Өзелгәнсең сиреньнән» (Н. Жиһанов музыкасы), «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Кем уйлаган» (Ж. Фәйзи музыкасы), «Бер тауда ун чишмә» (Ә. Фәттах музыкасы) кебек жырлар халык арасында зур популярлык казандылар.